МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.07.2021 г.Казань № 467

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 21 июлендә 7816 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 10 июлендәге 536 номерлы боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (дәвалау һәм шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениеләрендә) балаларны, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны ашатуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (дәвалау һәм шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениеләрендә) балаларны, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны ашатуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 10 июлендәге 536 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль

яклау министрлыгының 09.11.2015 №822, 07.06.2016 №317, 08.06.2017 №350, 15.11.2017 №803, 19.02.2018 №138, 15.05.2018 №368, 18.09.2018 №883, 20.06.2019 №487; 03.09.2019 №663, 12.11.2019 №987, 13.07.2020 №501, 09.10.2020 №716 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (дәвалау һәм шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениеләрендә) балаларны, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны ашатуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 1 июлендәге 467 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (дәвалау һәм шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениеләрендә) балаларны, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны ашатуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 10 июлендәге 536 номерлы боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (дәвалау һәм шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениеләрендә) балаларны, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны ашатуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләрнең әти-әнисенең берсе яисә әбисе, бабасы, опекуны (попечителе) тора:

1) медицина күрсәткечләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага йөрмәүче, 18 яшькә кадәрге балалар һәм яшүсмерләр, түбәндәгеләр исәбеннән:

эвакуацияләнгән көнне карында булганнарын да кертеп, читләштерү, күчерү зоналарыннан, читләштерү зоналарыннан күчерелгән, күчерелү хокукы белән яшәгән зоналардан эвакуацияләнгән;

компенсация бирер алдыннан күчерелү зонасында турыдан-туры аларның кимендә 1 ел; күченү хокукы белән яшәү зонасында кимендә 3 ел дәвамында даими яшәгән булу шарты белән, күченү зоналарыннан, күченү хокукы белән яшәгән зоналардан күчерелгән (туган урынына бәйсез рәвештә, ата-анасы (аларның берәрсе) бала туар алдыннан турыдан-туры әлеге зоналарда яшәгән (эшләгән) булу шарты белән, аларның балаларыннан тыш һәм туганнан соң баланың әлеге зоналарда даими яшәгән булу шарты белән, шулай ук 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 13 статьясының беренче өлешендәге 1-3 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән гражданнарның беренче һәм аннан соңгы буын балаларыннан тыш һәм Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә ата-ананың берәрсе радиоактив нурланыш алганнан соң туган балалардан тыш);

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы) 13 статьясының беренче өлешендәге 1-3 һәм 6

пунктларында күрсәтелгән гражданнарның беренче һәм аннан соң буын һәм Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә ата-ананың берәрсе радиоактив нурланыш алганнан соң туган балалар;

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә булган авария һәм Тичә елгасына радиоактив ташландыклар ташлану нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 175-ФЗ номерлы Федераль закон) 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбендә ата-аналары радиация йогынтысы нәтиҗәсендә авырудан интегүче гражданнарның беренче һәм икенче буын балалары;

2) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, дәвалау һәм шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениеләренә йөрүче балалар, түбәндәгеләр исәбеннән:

Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә яисә ата-анасының берәрсе радиоактив нурланыш алуның генетик нәтиҗәләре белән аңлатылган авырулардан интегүче;

175-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбеннән ата-анасы радиация йогынтысы нәтиҗәсендә авырулар белән интегүче гражданнарның беренче һәм икенче буыннары;

1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 13 статьясының беренче өлешендәге 1, 2, 3, 4 һәм 6 пунктларда күрсәтелгән гражданнар;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә нурланыш авыруы һәм барлыкка килгән башка авырулар нәтиҗәсендә үлгән гражданнар исәбеннән тукландыручысын югалткан гаиләләрдән, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә үлгән, 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 14 статьясында күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары кагыла торган инвалидларның гаиләләреннән;

нурланыш авыруы алган, барлыкка килүе яки катлауланувы 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация нәтиҗәсе белән аңлатылган авырулар исемлегенә кертелгән башка авыруларны алган, 175-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар исәбендәге гражданнар;

1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлану нәтиҗәсендә инвалид булган, 175-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясында күрсәтелгән гражданнар;

175-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 1-3 пунктларында күрсәтелгән гражданнар;

«Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт аркасында инвалид булган һәм нурланыш авыруы алган, барлыкка килүе яки катлауланувы 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация нәтиҗәсе белән аңлатылган авырулар исемлегенә кертелгән башка авыруларны алган гражданнар исәбендәге тукландыручысын югалткан гаиләләрдән, әгәр үлем очрагы 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыкларны ташлау аркасында радиация йогынтысының нәтиҗәсе булып торса;

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законы гамәлен аеруча хәтәрлек бүлекчәләрендәге гражданнарга тарату турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы Россия Федерациясе Югары Советы карарының (алга таба 0 2123-1 номерлы РФ Югары Советы карары) 1 пунктындагы «а« - «д» пунктчаларында күрсәтелгән аеруча хәтәрлек бүлекчәләрдәге гражданнар;

2123-1 номерлы РФ Югары Советы карарының 1 пунктындагы «а« - «д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар исәбендәге тукландыручысын югалткан гаиләләрдән.

Әлеге пунктта күрсәтелгән, хәзерге вакытта хәрби хезмәткәр, эчке эшләр органнары, җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең янгынга каршы федераль хезмәте, наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең әйләнешен контрольдә тоту органнары, Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләре, алар исәбендәге пенсионерлар, шул исәптән хәзерге вакытта эшләми торган (эш урыннарына бәйсез рәвештә), әлеге федераль башкарма хакимият органнарының граждан персоналы булган, шулай ук радиация йогынтысына дучар ителгән, салым полициясенең федераль органнарыннан куылган затлар исәбендәге пенсионерлар, шул исәптән эшләми торган (эш урыннарына бәйсез рәвештә) гражданнар исәбендәге затлар мөрәҗәгать итүчеләргә керми.»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Компенсация билгеләү турында гариза (гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән). Опекун (попечитель) мөрәҗәгать итүчегә акча күчерү өчен югарыда күрсәтелгән кредит оешмасында опекун (попечитель) тарафыннан ачылган номинал счет реквизитларын бирә;

2) социаль ярдәм чараларына хокук бирә торган таныклык күчермәсе;

3) чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

4) өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

5) тукландыручының үлемен дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

6) мөрәҗәгать итүченең радиоактив пычрану зонасы территорияләрендә яшәгән чорын раслый торган документ күчермәсе, – 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 7 статьясының өченче өлеше нигезендә Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиоактив пычрану зонасы чикләре кире каралган очракта яисә гражданнар күрсәтелгән зона чикләрендә даими яшәү урыны өчен күченгән очракта яисә әлеге зоналар чикләрендә эш урыны алмаштырылган очракта, әлеге Регламентның 1.2 пунктының 1 пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән гражданнарга бирелә

7) Чернобыль һәлакәте, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә ата-ананың берәрсенең радиоактив нурланыш алуы нәтиҗәсендә балада үсеш алган алган авыруларның сәбәпчел бәйләнешен билгеләү турында ведомствоара эксперт советы бәяләмәсе күчермәсе – әлеге Регламентның 1.2 пунктының 2 пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспорт (аны алмаштыра торган документ) күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләренраслый торган һәм мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклый торган документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге белешмәләр һәм документлар алына:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

балага опека (попечитель) билгеләнүе турында;

туендыручының үлемен дәүләт теркәвенә алу турында;

пенсия алу факты турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

уку процессы чорында мәктәпкәчә мәгариф оешмасына яки төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга баланың йөри алмавына сәбәпче булган медицина күрсәткечләренең булуы турында медицина учреждениесе белешмәсе (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен);

мәктәпкәчә белем бирү оешмасыннан (дәвалау яки шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениесеннән), белем бирү эшчәнлеген

гамәлгә ашыра торган дәүләт яки муниципаль оешмадан баланың әлеге оешмада (учреждениедә) торуы яисә белем алуы турында белешмә (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен);

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булса, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон рәвешләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш»;

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон формада вәкаләтле органнардан түбәндәге мәгълүматларны ала:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

туендыручының үлемен дәүләт теркәвенә алу турында;

пенсия алу факты турында.

3.4.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге документларны һәм белешмәләрне бирү турында вәкаләтле оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

туендыручының үлемен дәүләт теркәвенә алу турында;

балага опека (попечитель) билгеләнүе турында;

пенсия алу факты турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

уку процессы чорында мәктәпкәчә мәгариф оешмасына яки төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга баланың йөри алмавына сәбәпче булган медицина күрсәткечләренең булуы турында медицина учреждениесе белешмәсе;

мәктәпкәчә белем бирү оешмасыннан (дәвалау яки шифаханә тибындагы махсуслаштырылган балалар учреждениесеннән), белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган дәүләт яки муниципаль оешмадан баланың әлеге оешмада (учреждениедә) торуы яисә белем алуы турында белешмә;

Әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, документлар һәм белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.8.1 пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Үзәк бүлекчәсе белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».